КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 июнь г.Казань № 472

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2009 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 952 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1332 нче, 2022 ел, 21 сентябрь, 1022 нче, 2022 ел, 13 декабрь, 1321 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «44 326,0» саннарын «46 543,0» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «1,791» саннарын «2,189» саннарына алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «1,791» саннарын «2,189» саннарына алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «12 688,0» саннарын «13 323,0» саннарына алмаштырырга;

8 пунктның бишенче абзацында «премияләр» сүзеннән соң «,шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта «Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр» сүзләрен «Премияләр, шул исәптән аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен,» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктта:

бишенче абзацта «аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр» сүзләрен «премияләр, шул исәптән аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен,» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктның унынчы абзацында «бер сәгать тариф ставкасының 7 проценты күләмендә» сүзләрен «хезмәт законнары нигезендә билгеләнгән күләмдә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин